ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«15» апреля 2022г. №435

«Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан юынтык суны түгү (канализация) системасын Нурлат шәһәрен үзәкләштерелгән юынтык суларны агызып җибәрү системасына кертү турында

Россия Федерациясе Хекүмәтенең «Җирләрне яисә шәһәр округларын үзәкләштерелгән су чыгару системаларын (канализацияне) җирлекләрне яисә шәһәр округларын үзәкләштерелгән су чыгару системаларына кертү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 5 сентябрендәге 782 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 31 маендагы 691 номерлы карары, «Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәрен су белән тәэмин итү һәм суны агызып җибәрү схемасын раслау турында» Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 15 сентябрендәге 12 номерлы карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Промочистка» ҖЧҖ тарафыннан эксплуатацияләнүче юынтык суларны түгү (канализация) системасын, Нурлат шәһәренең үзәкләштерелгән суларны агызып җибәрү системасына кертергә.

2. «Нурлат шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә юынтык суны агызып җибәрү системасын чираттагы актуальләштерү вакытында Нурлат шәһәрен су белән тәэмин итү һәм суны агызып җибәрү схемасына, Нурлат шәһәренең үзәкләштерелгән су чыгару системасына кертүне күздә тоткан пунктны кертергә.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин